**Камаева Рима Бизяновна,**
*к.филол. н., доцент кафедры татарской филологии,*
*Елабужский институт К(П)ФУ,*
*г.Елабуга, Татарстан, Россия*
*e-mail: kamaeva-r@mail.ru*

УДК 81’373

# АНТРОПОНИМНАРНЫ РУСЧАГА ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ (ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ӘСӘРЛӘРЕ БУЕНЧА)

# ОСОБЕННОСТИ ПЕРЕВОДА АНТРОПОНИМОВ НА РУССКИЙ ЯЗЫК (ПО ПРИЗВЕДЕНИЯМ ТАТАРСКИХ ПИСАТЕЛЕЙ)

# FEATURES OF THE TRANSLATION OF ANTROPONYMS IN RUSSIAN LANGUAGE (BASED ON THE WORKS OF TATAR WRITERS)

**Аннотация.** В статье рассматривается особенности перевода антропонимов, взятых в качестве языкового материала из романов татарских писателей Н.Фаттаха, В.Имамова. Путем сравнительного анализа определяется приемы перевода личных имен на русский язык.

**Ключевые слова:** антропоним, индивидуальный стиль писателя, транскрипция, транслитерация.

**Abstract.** The article considers the features of translation of anthroponyms, taken as a linguistic material from the novels of Tatar writers N. Fattah, V. Imamov. By comparative analysis the receptions translation of personal names into Russian were considered.

**Keywords:** anthroponym, the individual style of the writer, transcription, transliteration.

Әдәби антропонимнар тирән мәгънә үзенчәлегенә ия. Алар персонажларны төрле яклап характерларга, контекстта тулырак ачарга, аңларга мөмкинлек бирәләр. Әдәби әсәр геройларына исемнәрне һәр язучы үзенчә сайлый, шуңа бәйле рәвештә язучының индивидуаль язу стиле турында да фикер йөртергә мөмкин. Кеше исемнәре, кушаматлар образ тудыруда мөһим роль уйный. Һәр исем нинди дә булса мәгълүмат алып килә. Кешенең исеме, кушаматы аның дәрәҗәсен, социаль хәлен, милләтен ачыкларга ярдәм итә. Әдәби әсәрләрдә антропонимнар чорны күзалларга, җирле колоритны тоярга мөмкинлек бирәләр.

Н.Фәттахның “Ител суы ака торур” (“Итил-река течет”, русчага М.Зарипов тәрҗемәсе), В.Имамовның “Казан дастаны” (“Казанская крепость”, русчага Б.Хәмидуллин тәрҗемәсе) романнарында антропонимнар күптөрле, алар рус теленә төрле юллар белән тәрҗемә ителгән.

Транскрипцияләү.

Романда күпчелек антропонимнар рус теленә транскрипция юлы белән күчерелгән. Мәсәлән: Минем йөрәгем урынында түгел, җылыйсым килә, – диде Аппак, читкә борылып [4, б. 267б]. У меня сердце не на месте, я сейчас заплачу, – проговорила Аппак [5, с. 246]. Тотыш йөрәгенә чыдый алмыйча сикереп урынынннан торды [4, б. 337]. Тотыш не утерпел, вскочив на ноги, стал быстро одеваться [5, с. 324]. Сал-Сал урмандагы котычкыч янгын давылы уртасында калган сыман зур хафага төште [1, б.167]. Сал-Сал испугался, будто оказался посреди чудовищного лесного пожарища [2, с. 246].

Транслитерацияләү.

Татар хәрефләре булган антропонимнар рус теленә транслитерациләү алымы белән тәрҗемә ителгән. Бу вакытта антропонимнардагы татар хәрефләре рус хәрефләре белән алмаштырып бирелә.

1. Ә хәрефе рус теленә а, е, и, э, я хәрефләре белән бирелә*: әмир Сәлмән – эмир Салман, вәзир Миңлебакир – визирь Миннибакир, сәрдәр Нуретдин – сердар Нуретдин, Айзирәк – Айзиряк, Мәрдән хәзрәт – Мердан хазрат, Күрәнби – Курэн-бий, Әмин – Эмин, Бәнат – Банат.*

2. Ө хәрефе рус теленә у, и, э, ю хәрефләре белән бирелә*: Мөхәммәт – Мухаммед, Зөлфия – Зульфия.*

3.Ү хәрефе рус теленә у хәрефе белән бирелә: Әбүгали – Абугали, Күрәнби – Курэн-бий, Күке – Кукэ.

4. ң хәрефе рус теленә н хәрефе белән бирелә: Тәңкә - Тэнэкэ, вәзир Миңлебакир – визирь Миннибакир, Шоңкар – Шункар,

5. һ хәрефе рус теленә г, х хәрефе белән бирелә: Ибраһим – Ибрагим, Маһитап – Махитап.

6. *Җ* хәрефе рус теленә ж хәрефе белән бирелә: Зөбәрҗәт – Зубаржат.

Транслитерацияләү вакытында түбәндәге хәрефләрнең дә чиратлашуы күзәтелә: е//у, и//у, и//е, е//э, е//я, ы//и, ы//у, о//у, ө//у, ә//и, п//б, д//т, ый/и, и//э. Мәсәлән: Тимер-Мөэмин – Тимур-Муэмин, Алмыш – Алмуш, Якуб-Ногман – Якуб-Нугман, Локман хәзрәт – Лукман хазрат, Ямгырчы би – Ямгурчи-бий, Шилке хан –

Шэлкэ-хан, Айкын-хатын – Айкун-хатын, Коркыт – Коркут.

– Әйе, син ахмак Коркыт! [1, б. 144]. – Эх ты, Коркут, глупец и ряззава! [2, с.146]. Аларның бер-берсен яратышулары Алмыш хан белән Айкын хатыннан башка беркем өчен дә сер түгел иде, ахрысы [4, б. 257]. Пожалуй, тайну эту не знали лишь Алмыш-хан да его старшая жена Айкун-хатын [5, с. 237]. Иң әүвәл әле Алмыш хан үз әләме, үз тирмәсе янына чакырып караган боларны [4, б. 33]. Еще Алмуш хан звал буртасовских беков под свои знамена, к своему шатру, но они отказались [5, с. 35].

Тәрҗемә телендә хәрефнең төшеп калу күренеше дә очрый. Мәсәлән: Габдулла – Абдулла, Гали – Али, Нургали – Нурали, Арыслан – Арслан, Габбас – Аббас, Насыйр – Насыр.

Арыслан бәк тәгаен чамалады: яңа әмиргә качак бәк кирәк түгел [1, б. 45]. Арслан бек тут же просек: новому эмиру вовсе не беглый бек нужен [2, с. 47]. Габдулла хан майлы калҗа өмет итеп исерде, күрәсең, алдын-артын карап тормый-нитми бар нөгәрен диварга ташлаттырды [1, б.13]. Абдулла хан, видимо, опьянел от предвкушения легкой добычи, и, не задумываясь, всем отрядом набросился на город [2, с. 14]. Насыйр Болгарда болгану-мәхшәрдән качып, хәзәрләрдә шымчылыкта йөреп кайткан кеше [1, б. 33]. Насир когда-то был лазутчиком среди хазар, покинув Булгарию в период волнений и смуты [2, с. 35]. Мөхәммәт авызын ачты:

– *Гали,* Әкрәм! – дип кычкырды ул үзенең йөзбашларына [1, с.47]. Мухаммед заговорил, по-прежнему резко:

– *Али,* Акрам! – подозвал он своих сотенных [2, с. 49].

Җукәтауга, Габбас ышыгына, энекәше куышына кереп качкан [1,б. 66]. Только потом сообщили – спрятался у брата своего Аббаса, в Джукатау [2, с. 67].

Аңлатып бирү юлы белән тәрҗемә итү.

Аңлатып бирү юлы белән тәрҗемә иткәндә оригиналь әсәрдәге антропоним шул персонажга хас характерлы сыйфатлар белән аңлатылып бирелә. Мәсәлән: кызга – к своей возлюбленной Аппак*, Күрән бинең – у предводител*я рода Курен-бия, әмир Сәлмән – эмир Салман из Ошеля, Борак – Борак, воевода и правая рука.

1.Амбарлар белән бергә Күрән бинең йөрәге дә бушап калган иде [4, б.104]. Опустели хранилища, пусто и неприютно стало на сердце предводителя рода Курен-бия [5, с. 103]. 2. Әмир Сәлмән илле мәргәне белән килеп җитә [1, б. 5]. Эмир Салман из Ошеля прибудет с полусотней лучников [2, с. 5]. 3. Янда Хәдичә бөтерелеп йөри [1, б. 6]. – Вокруг волчком вертится верная и незаменимая Хадича. [2, с. 7]. Сарай ишегеннән Борак килеп керде [1, б. 7].– В дверях дворца показался Борак, воевода и правая рука [2, с. 7].

Лексик алмаштыру.

Антропонимнарны кайбер очракта тәрҗемәче апеллятив лексика белән алмаштырган. Мәсәлән: Утташ камның бөтенләй кирәкмәгән юлдан китүен аңласалар да, аның сүзен бүлдерергә беркемнең дә йөрәге җитмәде [4, 87б.]. Однако пойти против шамана не смели [5, 71 б.].

Бу ысул белән тәрҗемә иткәндә сүзнең мәгънәсе тараю яки, киресенчә, сүз мәгънәсенең киңәюе күзәтелә. Тәрҗемәдә кеше исеменең алмашлык ярдәмендә бирелүе дә еш очрый. Тотышның кинәт башы әйләнде, йөрәге суга башлады [4, б.146]. У него кружилась голова, сильно колотилось сердце... [5, с. 14].

Антропонимнар әдәби әсәрләрдә кешенең һөнәрен, титулын, характерлы сыйфатларын белдерүче сүзләр белән бирелгән. Тәрҗемә вариантында мондый сүзләр калькалаштыру, транслитерацияләү юлы белән тәрҗемә ителә, төшереп калдыру ысулы да кулланылган, кайбер өстәмәләр белән бирү дә күзәтелә.

Мәсәлән: Алмыш ханның оныгы Габдулла таҗдар – правитель Абдулла, внук знаменитого хана, Казаяк ыруының башы Ямгырчы би – предводитель рода Казаяк Ямгурчи-бий, Нур-Суар каласының олугбәге Талиб Шәмси– улугбек города Нур-Сувар Талиб Шамси, Даян вәзирнең малае Хәзәр Насыйр – Насир-Хазарин, сын визиря Даяна, сыңар колак Торымтай – одноухий Торымтай, Җүкәтаудан килгән сәүдәгәр Минасның чем-кара чәчле кызы Сания – черноволосая Сания, дочь купца Мираса из Джукетау.

Тикшерүләр күрсәткәнчә, антропонимнар рус теленә транскрипцияләү, транслитерацияләү ысуллары ярдәмендә тәрҗемә ителәләр. Шулай ук төшереп калдыру ысулы да кулланылган, антропонимнарны рус телендә кайбер өстәмәләр белән бирү дә күзәтелә.

### Әдәбият


1. Имамов В.Ш. Казан дастаны: Тарихи роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 240 б.
2. Имамов В.Ш. Казанская крепость. Исторический роман. Перевод с татарского Булата Хамидуллина. – Ижевск: ГУПУР «Ижевская республиканская типография», 2005. – 240 с.
3. Камаева Р.Б. Слова-реалии в татарской художественной литературе и способы их перевода на русский язык // В мире научных открытий: социально-гуманитарные науки. – Красноярск: Изд-во “Научно-инновационный центр”, 2015. – №11(71) – С. 244-249.
4. Фәттахов Н.С. Ител суы ака торур: Тарихи роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 398 б.
5. Фаттахов Н.С. Итиль-река течет: Роман. Переводчик Зарипов М. – Казань: Татар. кн. изд-во., 1978. – 367 с.